**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге составына керүче Кайбыч торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

05.11.2025 № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Кайбыч авыл җирлегенең Кайбыч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү; яктырткычлар сатып алу; Кайбыч авылында балалар мәйданчыгын төзекләндерү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 05 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыененың нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны-406 кеше. Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 298 катнашучы кертелде. Тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны-160 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 150 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 10 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге составына керүче Кайбыч авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Кайбыч авыл җирлегенең Кайбыч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү; яктырткычлар сатып алу; Кайбыч авылында балалар мәйданчыгын төзекләндерү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Кайбыч авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кайбыч авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ___________ С.И.Нуретдинова

Кайбыч авыл җирлеге
башлыгы ___________________ С.И.Нуретдинова